**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

«24 » август, 2023 ел

№ 623

«Җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү хокукын бирү хакында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 05 октябрендәге 347 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2023 елның 21 июлендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. 1.4 пунктын Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының режим кысаларында чараларны гамәлгә ашыруны күздә тотучы таләпләрен үтәмәү (база әзерлеге дәрәҗәсе)» Татарстан Республикасы КоАП 2.21 статьясын өстәргә.
2. Әлеге карарның башка пунктларын үзгәрешсез калдырырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/www.pestreci.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе В.И. Никитин